***МИССИОНЕРСКИЙ ЛИСТОК***
***КРЯШЕНСКАЯ ДУХОВНАЯ МИССИЯ (http://www.missiakryashen.ru)***

# ÖЛÖШ АЛЫУ (ДАРЫ ЭЧЕЎ) ЖЯШЕРЕГЕ



Бу оло Жяшерекне священник Литургия дигян келяўдя кыла. Священник теляге арткылы, Алла Улынын сюзляре буйынча Святый Тын кыуаты белян, престол öстöндяге икмяк Христос Тяненя алмаша, жимеш сыуы (вино) Христос Канына алмаша. Алар кюз кюрергя икмяк булса да, жимеш сыуы булса да, аларны Ходай Ўз кодряте белян Христоснын Тяне, Каны итя. Христоснын шушы куркынычлы Жяшерекляреннян öлöш алган кеше, жазыклары кичерелеб, Иисус Христос белян кушыла, мянге тормошло була. Ходай Ўзе áйткян: *«Тянемнян, Канымнан öлöш алыучы мянге тормошло була»* (Ин. 6, 54), дигян. Бу öлöш алыу Жяшереген иң элеке Ходай Иисус Христос Ўзе кылган. Ул öйрянеўчеляреня икмякне биреб áйткян: *«Алыгыз, ашагыз, бу Минем сезнен öчöн, жазыклар кичерер öчöн, уалынган Тянем»*, дигян. Аларга тагы сауыт белян жимеш сыуы биреб áйткян: *«Бу сауыттан барыгыз да эчегез, бу Минем сезнен öчöн, кюб кешеляр öчöн жазыкларны кичерергя агызган жаңа килешеў Каным,* дигян. Аннары ул Жяшерекне жалан кыларга Апостолларга кушкан.

Изге Жяшереклярдян öлöш алырга барыучы ўзенен Алла алдында жук кна нястя икянен, жараусыз булыуын, жазыкка батканнығын тöбöннян аңнарга тейеш, барысы белян дя татыуланышырга, ўзен усаллыктан, кешене гайебляўдян, äр-тöрлö киряксез уйлардан, сюзляр сöйляўдян тыйылырга тейеш. Булдыра алганча, жангызырак калыб, Евангелиене, «Öлöш алыу алдыннан укый торган теляк ряте» иманнарны укырга тейеш.

Изге öлöш алыу Жяшерегеня ўзенне бер öч кöн ураза тотоб äзерлярґя киряк. Ураза тотоу теляк итеў белян бергя бара. Ураза ашы булмаган ит, май, сöт, кюкяй ашамныкларын ашау бöтöнняй тыйыла, бютян ашамныклар да тыйылыбрак, äзряк ашала. <u>Чиркяўдя чумылган кешегя гня Öлöш алырга жарый.</u>

Öлöш алырга барыучы келяў башлангынчы священник алдында жазыкларын áйтергя тейеш. Жазык áйткян чакта священник сораганны кöтмöйче, узеңне ичтя дöрöслямейче, гайебне бютянняргя ауыштырмыйчы, жанынны ауырайтыб торган нястялярне ўзен áйтеб бирергя киряк.

***Ниндей жазыклар була:***

Алланы хурлау, Аңарга зарланыу, чиркяўлярґя жöрмяў, олосомаклык, кöпöрлöк, кюремчеляргя, гороскопларга ышаныу, исереб жöрöў, атна кöннö эшляў, сюгенеў, ураза тотмау, теляк итмяў, алдалау, кешене рянжетеў, кешедян мыскыл итеў, кеше ўтереў(аборт), кыйнау, каргау, ызгышыу, ачыулык, уйнашлык итеў, жат ир (хатын) белян азгыннык итеў, азгын няпесле уйлар тотоу, кюнелдя уйнашлык итеў, кеше тикшереў, кеше сöйляў, кешене жаманнау, урлау, кöнчöлöк итеў, ўбкяляў, кеше кайгысына сöйöнеў, ўзенне ўзен мактау, мал жыйыу, малга биренеў, тянгя гня жарарга тырышыу, башка жазыклар…

***Öй-хужалыгында кулланмаска!***